
# *Хәсән Туфан*

# ***(1900-1981)***

алга



***...Бирде дөнья кирәкне, Еламаска өйрәтте... Кайсыгызның кулы җылы? – Бәйлисе бар йөрәкне...***

алга

Туган җире

Шагыйрь үзе турында (анкета)

Шагыйрь турында замандашлары

Х.Туфанның гаиләсе

Хәсән Туфан истәлекләреннән

Хәсән Туфанның иҗатташлары, дуслары

Хәсән Туфан образы сәнгатХәсән Туфан образы сәнгатьХәсән Туфан образы сәнгатьтә


Хәсән Туфан музеенда

Хәсән Туфан китаплары

ШагыйрШагыйрь Шагыйрь исеме мәңгелек

Хәсән Туфан иҗаты һәм тормышы буенча белемнәрне тикшерү. Тест

кире




**Татарстанның хәзерге Аксубай районында Иске Кармәт исемле авыл бар, гадәти татар авылы. Менә шушы авылда 1900 елның 9 декабрендә әти-әнисенең соңгы, унынчы баласы булып, Хисбулла исемле малай дөньяга килә. Тарих аның исемен үзгәртеп китапларына "Хәсән" – дип язар, фамилиясен "Туфан" дип танытыр...**

кире

**Исемегез** – ***Хәсән***

**Әдәби кушаматыгыз** – ***Туфан***

**Туган вакытыгыз** – ***1900 елның 9 декабре (иске стиль белән 27 ноябрь)***

**Туган җирегез** – ***элекке Казан губернасы, Аксубай волосте, Кармәт авылы***

**Белемегез** – ***Уфадагы "Галия" мәдрәсәсе, үзлегемнән уку***

**Эшләгән эшләрегез** – ***бакырчы-шахтер, токарь, слесарь, укытучы, журналист***

**Матбугатта басыла башлавыгыз** – ***1924 ел***

**Язучылар союзына алыну вакытыгыз** – ***1934 ел***

**Бүләкләрегез** – ***Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Татарстанның Г. Тукай ис. дәүләт премиясе***

алга

Әдәби остазларыгыз – ***Лермонтов, Хәйям, Тукай, Ибраһимов, Маяковский, Есенин, Багрицкий...***

Яраткан шагыйрьләрегез – ***Такташ, Твардовский***

Яраткан мавыгуыгыз – ***чәчәкләр үстерү, сәгать төзәтү***

Кайсы вакытта иҗат итәргә яратасыз – ***төнлә белән...***

Нинди кара белән язарга яратасыз – ***яшел белән***

Иң бәхетле чагыгыз – ***иҗади накалда яшәгән чак Җанның, күңелнең, йөрәкнең, бәгырьнең дөрләгән, кайнаган чагы, уй һәм хиснең аера алмаслык булып кушылып ташып торган чагы***

Укучыга әйтәсе сүзегез –

***Ничек икән синең йөрәк? дисәң,***
***Ничек икән гомер көннәрең? –***
***Кулыңдагы китабымда, чордаш,***
***Шигырьләрдә – минем йөрәгем.***

кире

# Шагыйрь турында замандашлары

**1927 ел. Шагыйрь Һади Такташ:**

**«Соңгы вакытта Туфан үзенең шигырьләре эчендәге сирәк, ләкин яшь, яңа хисләре, күп вакытта гакыллы тирән хисләре белән җанга җылылык кертә башлады. Анда зәңгәр яшьлек хисләре бөдрәләнә. Чәчәгеннән бигрәк җимешле агач булыр ул...»**

**1966 ел. Шагыйрь Сибгат Хәким:**

**«Туфан – авыр, катлаулы юл үткән, татар поэзиясенең зурлыгын гел сиздереп торган, Такташлар чорын бүгенге белән нык тоташтырган бердәнбер олы фигура. Татар поэзиясендә Туфан бер генә, башка Туфан юк!»**

алга

# 1964 ел. Болгария укучысының шагыйрьгә язган хатыннан:

«Бер китапханәдә рус телендәге китапларны актарганда, сезнең җыентыкка күзем төште. Нинди шигырьләр икән дип, берничәсен укып карамакчы булдым. Моңа кадәр сезнең шигырьләрне укыганым юк иде. Хәер, гафу итегез, татар халкының шундый яхшы язучылары барлыгын да белми идем. Нигә яшерергә, хәтта әдәбиятыгызның барлыгын да белми идем. Бәлки шуңа күрәдер дә, минем шатлыклы гаҗәпләнүем сезнең хөрмәтле халкыгызга – миңа таныш булмаган татар халкына – туганлык мәхәббәтенә әверелде. Янымда бер буш конверттан башка кәгазь юк иде. Шул конвертка “Сиңа” дигән шигырегезне күчереп алдым. Мәхәббәт турында шундый кыска һәм шундый үзенчәлекле итеп моңа кадәр әле берәүнең дә язганы юктыр дип уйлыйм.»

алга

**1970 ел. Әдип Гомәр Бәширов:**

**«Шагыйрьләр хакында сүз чыкканда, гадәттә, поэзия өчен яши, диләр. Х.Туфанны исә мин ул үзе шигырь булып яши дияр идем. Чөнки Туфанны шигърияттән, шигырьне Туфаннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул шигъри образга, шигърият дөньясына гашыйк кеше. Шигырьнең теләсә нинди киртәләрне җимерерлек тылсымлы көче барлыгына Туфан кебек чын күңелдән инанган башка кешене мин белмим.»**

**1978 ел. Рус совет шагыйре Михаил Дудин:**

**«Хәсән Туфан – поэзиядәге сирәк очрый торган, гаҗәеп, уникаль күренешләрнең берсе. Ул – татар халкының горурлыгы. Кадерен белегез аның, саклагыз аны!»**

кире

# Х.Туфанның гаиләсе



Сулдан – Хәсәннең әтисе Фәхри-Таһир, Зөфәр абыйсы, Мөхетдин абыйсы (1966 елда вафат), Мөхетдиннең кызлары, Фәхри-Таһир хәзрәтнең улы Сәгыйтьнең улы. Хәсәннең әнисе. Галим Гайнетдин әфәнденең әйтүенчә, бу рәсем Фәхри-Таһир хәзрәтнең Пермь ягындагы Лысьва төбәгендә имам булып торган чагында алынган булуы ихтимал.

кире

# Хәсән Туфан истәлекләреннән

Әнисе язу яза белмәсә дә, шигъри җанлы кеше була. Шагыйрь аның турында болай дип искә ала: «Дөньяның, табигатьнең матурлыкларын күрергә иң әүвәл әнием өйрәтте мине. Белеп, максат итеп түгелдер, әлбәтттә, ә үзе шундый үтә нечкә күңелле, үтә шигъри җанлы булгангадыр, тормышның безне чолгап алган ямьсез якларын минем күздән яшерергә, күңел күземне табигатьтәге ямьлелекләргә юнәлтергә тырышкан булган күрәсең ул. Мине йортка яки бәрәңге бакчасына алып чыга да дөнья күрсәтеп йөри, кайткан яки киткән кыр казлары, торналар белән генә түгел, куаклар, үсемлекләр, иҗлләр, йолдызлар белән дә сөйләшә башлый иде. Йолдызларны танырга, табарга өйрәтә, аларның исемнәрен әкиятләргә кушып сөйли иде. Әни миндә табигатьтәге бар нәрсәнең җаны бар икән, чишмәләр генә түгел, йолдызлар да, җилләр дә сөйләшә икән дигән “иман” тудырды ».

алга

**“Авыл малае нәрсәләр белергә һәм эшләргә тиеш булса, мин дә шуларның барысын башкардым: иген урдым; печән чаптым, чабатаны үзем үреп кидем, сәгатьләр төзәтеп, тәрәзәләргә пыялалар куеп йөрдем, алачыкка йөреп тимерче булырга өйрәнә башладым”.**

алга

**Салкын кышның озын төннәрендә авыл малайлары җылы мунчаларга җыелып “мошагарә” – җыр әйтешү ярышлары үткәрәләр. Малайлар арасында еш кына үзара бәрелешләр булып алгалый. Бер көнне шулай бәрелеш вакытында Хисбулла каршы як малайларга атап “җыр” чыгара.**

**“Менә шунда җырның йодрыктан көчлерәк икәнен төшендем бугай. Бу “вакыйга” шигырьгә “килә” башлавымның беренче чагылышы булгандыр бәлки”, – ди шагыйрь үзенең истәлекләрендә.**

алга

“1914 елның язында Уралга, бакыр казый торган абыйлар янына киттем. Ул вакытларда мин авылдан бөтенләй китүемдер дип һич уйламаган идем” – дип яза Хәсән. Юк, бакыр чыгару “баеп” була торган эш булмаганын Хәсәннең абыйлары яхшы аңлыйлар һәм үзара киңәшкәннән соң кече энеләрен – укуга җибәрергә карар кылалар. Шулай итеп, Туфан Уфага, “Галия” мәдрәсәсенә, хыялындагы яңа дөньяга китеп бара.

“Галия”дә, татар-башкорт халыкларының ирек сөюче, кыю, зирәк уллары арасында, Төркестан кышлакларыннан, казак далаларыннан, Кавказ тауларыннан, Кара диңгез ярларыннан килгән укучылар арасында күкрәп торган яшьлек дөньясы мәйданында яши башладым” – дип искә ала.

алга

Хәсән “Галия” мәдрәсәсе шәкерте 1916 ел




алга

**“Галия”дә укуның икенче елында Туфан киләчәгендә юнәлеш бирәчәк остазы Галимҗан Ибраһимов белән очраша.**

**“Бервакыт ул безне дәрестән тыш эш биреп, үзебез теләгән темага инша язып килергә кушты. Мин авылыбызда күргән бер вакыйга рәвешендәге бернәрсә итеп язып китердем. Галимҗан абый аңа “бик яхшы” дигән билге куйган һәм “хикәям” астына “Сездә язучылык сәләте барлыгы чагыла, шул эшкә әзерләнергә кирәк, бәлки язучы була алырсыз” рәвешендәрәк киңәшләрен язган иде”.**

**алга**

Х. Туфан
1923 ел



алга

**1928 елның язында Урта Азия һәм Кавказ халыкларының тормышларын өйрәнергә теләп җәяүләп сәяхәткә чыгып китә.**

**“1930 елда Ташкентта һич көтмәгәндә “үзем” белән үзем очраштым. Назыйм Хикмәтнең төрек телендәге мәҗмугасын эзләп китапханәгә кердем. Шуны эзләгәндә “Х.Туфан шигырьләре” дигән китапны күреп хәйран калдым. Кем бу, нинди Туфан икән соң бу? – дип аптырап калдым. Ачып карасам, минем шигырьләр. Иң якын киңәштәшләрем, ярдәмчеләрем булган Галимҗан Нигъмәти белән Гомәр Гали Казанда сайланма җыентыгымны чыгарганнар икән ләбаса”.**

Ашхабадтан Алтайга таба сәяхәт иткәндә. “Юлның басмачыларда икәнен белгәч, Сырдәрья аша чыгып, Ташкентка юнәлдек.” Х.Туфан уртада. 1929 ел



алга

# Хәсән Туфанның сөекле хатыны, артистка Луиза Салигаскәрова



алга

# Хәсән Туфанның иҗатташлары, дуслары



Шигърият “арысланнары” Аккош күле буенда. Утырганнар (сулдан): Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи. Басып торалар (уңнан): Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур. 1940 ел, июнь

алга

Хәсән Туфан (уңнан беренче), Сибгат Хәким (сулдан өченче), Нәби Дәүли (сулдан өченче) Сабадагы “Мишә дулкыннары” исемле әдәби берләшмә әгъзалары белән. Уңнан өченче – берләшмәне оештыручы, чирек гасырдан артык аның җитәкчесе, балалар язучысы Газиз Нәбиуллин. 1960 ел



**алга**



Сулдан уңга (утырганнар): Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Бакый Урманче.
Басып торучылар: Нажар Нәҗми, Әмирхан Еники Исәнбәтләрдә кунакта.
1980 ел


алга



Язучылар Союзы съездында. Алгы планда язучы Гариф Ахунов, икенче рәттә Хәсән Туфан

алга

# Туфан сагышы




кире

# Хәсән Туфан образы сәнгатьтә



алга

Хәсән Туфан. Исеме билгесез рәссам тарафыннан ясалган рәсем. 1930 еллар тирәсе






Туфан. Марсель Галиев иҗат иткән рәсем

алга





Хәсән Туфан сурәте.
Б.Урманче. 1970



**Х. Туфан. Рәссам Мансур Рәхимов эше**

# Хәсән Туфан портреты.
# Рәшит Имашев





**кире**

# Хәсән Туфан








**музеенда**

**алга**





алга


КАЗАНЬ
ТОРЖЕСТВЕННОЕ ПРОВОЗГЛАШЕНИЕ
ФЕРМАНА
ИДЭЛЬ-УРАЛЬСКОЙ
РЕСПУБЛИКИ







алга










алга










алга


# Хәсән Туфан китаплары

















алга


# Шагыйрь исеме мәңгелек






**Яр Чаллы шәһәрендә**
**Хәсән Туфан проспекты**

алга



кире

Шагыйрь Хәсән Туфанның кабер ташы

# Хәсән Туфан иҗаты һәм тормышы буенча белемнәрне тикшерү

1 **Хәсән Туфанның туган ягы:**

- А. Аксубай районы Иске Кармәт авылы
- Ә. Тобол губернасы Лысьва шәһәре
- Б. Казан шәһәре

2 **Хәсән Туфан шәкерт булып укыган мәдрәсә:**

- А. Оренбургтагы “Хөсәения”
- Ә. Казандагы “Мөхәммәдия”
- Б. Уфадагы “Галия”

3 Хәсән Туфан әдәбият дәресләрен кемнән ала?

- А. Габдулла Тукай
- Ә. Галимҗан Ибраһимов
- Б. Шәехзада Бабич

алга

4 Хәсән Туфан җәяүле сәяхәт иткән яклар:

А. Урта Азия һәм Кавказ

Ә. Урал һәм Себер

Б. Кавказ һәм Урал

5 Бу юллар Х.Туфанның кайсы шигыреннән алынган?

*...Әгәр тагын килсәләр:*
*- Сау! – дип хәбәр бирсәләр,*
*Вулканнарга керер идем,*
*Шундадыр ул... дисәләр.*

А. Илдә ниләр бар икән?

Ә. Кайсыгызның кулы җылы?

Б. Сез кемнәр?

**алга**